| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Яңа Элмэле авылы

29 октябрь 2021 ел № 12/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
Районы Яңа Әлмәле авыл җирлеген төзекләндерү
Кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Конституция судының 19.04.20021 ел, № 14-П карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Советының 2017 елның 19 сентябрендәге 25/2 номерлы карары (2018 елның 27 мартындагы 33/1 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләренең 135.13 пунктына " тиешле тәртиптә оешкан һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләре милекчеләреннән тыш һәм әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса;" сүзләрен өстәп үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Яңа Әлмәле авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгына йөкләргә .

Татарстан республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков